Р Е С П У Б Л И К А  Т А Т А Р С Т А Н
**Г Л А В А**
**Большебуртасского сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**м у н и ц и п а л ь н о г о  р а й о н а**

422833, с. Большие Буртасы, ул Ленинградская 27
тел./ факс (8-843-77) 33-6-42
ОГРН 1021605953016
ИНН/КПП 1622001795/162201001

Т А Т А Р С Т А Н  Р Е С П У Б Л И К А С Ы
***Кама Тамагы***
**м у н и ц и п а л ь  р а й о н ы**
**Олы Бортас авыл жирлеге**
**Б А Ш Л Ы Г Ы**

422833, Олы Бортас авылы, Ленинград ур 27
тел./ факс (8-843-77) 33-6-42
ОГРН 1021605953016
ИНН/КПП 1622001795/162201001

**Постановление** **Карар**

**от 03.12. 2019г.** **№24**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлегенен Кече Бортас авылы пунктында «Халык җыенын билгеләү, акчаларны кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнардан үзара салым җыю»

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Бортас авыл җирлеге Уставы 24.1 статьясына туры китереп карар бирәм:

1. 2019 елның 14 декабрендә 10 сәгать 00 минутка үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының беренче этабын түбәндәге адрес буенча Кече Бортас авылында яшәүчеләр катнашында билгеләргә: Кече Бортас авылы, Гагарин урамы, 1-10 нчы номерлы йортлар очен.
2. 2019 елның 14 декабрендә 10 сәгать 30 минутка үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын түбәндәге адрес буенча Кече Бортас авылында яшәүчеләр катнашында билгеләргә: Кече Бортас авылы, Гагарин урамы,13- 15 нче номерлы йортлар очен.

3. 2019 елның 14 декабрендә 11 сәгать 00 минутка үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының оченче этабын түбәндәге адрес буенча Кече Бортас авылында яшәүчеләр катнашында билгеләргә: Кече Бортас авылы, Һ. Такташ урамы, 18 – 23 нче йортлар, х. Ямашев урамы, 31-37 нче йортлар, Волгоград урамы, 17йорт, 25-30 нчы йортлар, 38-нче номерлы йортлар очен.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2020 елда Кама Тамагы муниципаль районының Олы Бортас авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә килешу һәм түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, алынган акчаларны юнәлтүгә ризамы:

1. Кече Бортас авылы эчендәге (җәйге-көзге чор) чүп үләннәрен чабу.

2. Кече Бортас авылы зиратына вак таш түшәлгән юл салу.

3. Кече Бортас авылының Гагарин урамындагы "кечкенә Улак" чишмәсе корылмасын ремонтлау.

«ӘЙЕ» «ЮК»

5. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Олы Бортас авылы, Ленинград урамы, 27;
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Балчыклы авылы, Ленин урамы, 70 нче йорт, һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Бортас авыл җирлеге башлыгы Р. С. Сәгдиев